РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

СОВЕТ ТИМЕРШИКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422057, Республика Татарстан, Сабинский район,
с.Тимершик, ул. Пионерская, 19 а
тел. (84362)2-23-23

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТИМЕРШЫК АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422057, Татарстан Республикасы,
Саба районы, Тимершык авылы,
Пионер урамы, 19 а йорт
тел. (84362)2-23-23

e-mail: Timer.Sab@tatar.ru

---

РЕШЕНИЕ
23.10.2024

КАРАР
№18

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге Советының 08.11.2021 №24 карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контроле турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Һава кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 08.08.2024 елгы №289-ФЗ Федераль закон нигезендә Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге Советының «Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында» 08.11.2021 №24 карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контроле турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4.6.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.6.3. Планнан тыш күчмә тикшерү прокуратура органнары белән килешү буенча гына үткәрелергә мөмкин «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248 - ФЗ номерлы Федераль законның 1 өлешендәге 3-6 пунктлары, 57 статьясындагы 3 өлеше һәм 66 статьясындагы 12 һәм 12.1 өлешләре нигезендә аны үткәрү очракларыннан тыш».;

1.2. 4.9.4. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.9.4. Әлеге Нигезләмәдә 4.2.1. пунктының 2 пунктчасында каралган урынга барып тикшерү нәтиҗәләре буенча карар кабул ителергә тиеш түгел.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Саба

муниципаль районы Тимершык авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/timershik адресы буенча рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакытыннан үз көченә керә.

Тимершык авыл
җирлеге Башлыгы А.Х. Хаҗиев